# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 3 10.12.2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге составына керүче Баек торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенә керүче Баек торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 900 (тугыз йөз) сум күләмендә, көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 450 (дүрт йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Баек авылы юлларын ремонтлау һәм карап тоту.
- Баек авылында Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү урыннарын төзекләндерү, электр белән тәэмин итү җайланмасы алу, бүләкләр сатып алу.
- Баек авылында массакүләм чаралар үткәрү өчен бүләкләр сатып алу (Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, 23 февраль; 8 Март; юбилярларны котлау, спорт ярышлары уздыру өчен чыгымнар, ритуаль хезмәтләргә чыгымнар).
- Баек авылына урам яктырткычлары сатып алу.
- Баек авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү.
- Баек авылында аз керемле гаиләдәге балаларга ярдәм итү.
- Баек авылы мәдәният йортын ремонтлау.
- Баек авылында Атау урамының күперен ремонтлау һәм перила урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу.
- Баек авылы зиратының коймасын ремонтлау.
- Баек авылы чишмәсен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Баек авылы, Совет урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында

халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Баек авыл җирлеге башлыгы** **Ф.М.Фахерлегаянов**